Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма комитеты

КАРАР № 1

20 февраль 2021 ел

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәрендәге идарәсе (районара) Дәүләт учреждениесенең 2021 елның 19 гыйнварындагы БЛ-08-01-12/242 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Борискино авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2021 елның 1 февраленнән 6 424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын билгеләү турында» гы Борискино авылы башкарма комитетының 2020 елның 22 апрелендәге 1 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Борискино авылы Үзәк урамы, 61 нче йорт; Березовка бистәсе, Үзәк урамы, 16 нче йорт территоиясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2021 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Борискино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма
комитетының 2021 елның
20 февралендәге 1 нче
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 91,02 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3689,02 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 573,12 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2071,82 |
| Барлыгы | | 6424,98 |

Борискино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма
комитетының 2021 елның
20 февралендәге 1 нче
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 91,02 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен тәрү | 2162,78 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1526,96 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 573,12 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2071,81 |
| Барлыгы | | 6424,98 |

Борискино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов